**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1141**
**22.02.2024**

Башкарма комитетның 2017 елның 24 августындагы 4960 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Ихтыярый янгын сагы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 445-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында» 2017 елның 24 августындагы 4960 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2022 елның 1 сентябрендәге 4430 номерлы Карары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәгә, 2 пунктның 7 һәм 8 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«7) ихтыярый янгын сагы - аларның эшчәнлеге янгыннарны профилактикалауда һәм (яки) сүндерүдә һәм авария-коткару эшләрен үткәрүдә катнашуны күздә тота торган ихтыярый янгын сагы иҗтимагый берләшмәләрен, объектлы ихтыярый янгын сүндерү бүлекчәләрен һәм аларның составына керүче ихтыярый янгын сүндерүчеләрне үз эченә алган, ихтыярый эшчәнлеккә нигезләнгән янгын сагының төре;

8) ихтыярый янгын сүндерүче - ихтыярый янгын сүндерү бүлекчәсе составында ихтыярый һәм түләүсез нигездә янгыннарны профилактикалауда һәм (яки) сүндерүдә һәм авария-коткару эшләрен үткәрүдә катнашучы физик зат.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов